**КУРКЫНЫЧ ТӨТЕН**
Начар гадәт өлкәннәрдән үсмерләргә күчкән
> 2

**ӨМЕТ ЯШӘТӘ**
13 бала анасы Гөлфирә Каюмова 3 улын махсус хәрби операциядән көтә
> 4

**ӘТИ СҮЗЕ**
50 елдан соң улы әтисенең каберен эзләп таба
> 5



**ХА-ХА-ХАНӘ**
Булмас, димә, кызык-мызык, фототөрткеләр монда
> 6


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 180 (29147) | Чәршәмбе | 6 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

# ЯҢА КЫШТА – ИСКЕ БӘЯ

**Яшәргә өйрәнәбез**

**Бу кышта ут һәм су өчен узган ел ук расланган тарифлар буенча, ягъни былтыр ничек түләсәк, шулай исәп-хисап ясаячакбыз. Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта әнә шул хакта искәрттеләр. Чираттагы кыйммәтләнү 2024 елның 1 июленә билгеләнгән. Тарифларның күпмегә артасын да әйттеләр.**

Билгеле булганча, тарифлар гадәттә елга бер тапкыр – җәй көне артса да, 2022 ел азагында, ил Хөкүмәте карары нигезендә, коммуналь хезмәтләргә бәяләр бер ел эчендә икенче тапкыр артты. Аның каравы 2023 елның җәендә тарифлар үзгәрешсез калды.

– Бер ел ярымлык «тынлык»тан соң, бәяләр кабат 2024 елның 1 июлендә кыйммәтләнәчәк, – диде Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев. – Федераль канун таләпләре нигезендә без агымдагы елның 20 декабренә кадәр киләсе елга тарифларны расларга да тиеш. Аларны исәпләү Россия социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләреннән чыгып башкарыла.

Озын сүзнең кыскасы, киләсе елның 1 июленнән коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр Татарстанның күпчелек районнарында – күп дигәндә 10,8, ә республиканың аерым муниципаль берәмлекләрендә 15,7 процентка кадәр артачак.

Республиканың төрле районнарында ут яки суга тариф аерыла, шуңа күрә бәяләр дә төрле, дип ачыклык керттеләр брифингта. Питрәч авыл җирлеге мисалында исәпләп карыйк: киләсе җәйдә анда су – 7,9, пычрак суларны агызу – 9,5, ут – 8,8, җылылык – 14, газ – 11,2, каты көнкүреш калдыкларын чыгару бәясе исә 4 процентка артачак. Авыл җирлеге буенча тарифлар уртача 11,3 процентка кыйммәтләнәчәк дигән сүз.

Аерым алганда, 2024 елның 1 июленнән халык өчен «зәңгәр ягулык»ның бер куб метры 11,2 процентка индексацияләнеп, 7,54 сумга җитәчәк. «2023 елда Татарстан халык өчен газ тарифлары буенча ил төбәкләре арасында арттан дүртенче урында иде», – диде дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев бу хакта сөйләгәндә.

Ул «зәңгәр ягулык» бәясенең нәрсәләрдән җыелуын да аңлатты.

**Фикер**

**Наталья БУТАЕВА, Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары:**
– Татарстанда халыкка ярдәм итү максатыннан, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә социаль ярдәм чаралары каралган. Аерым алганда, коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары гомуми айлык керемнәренең 21 процентыннан артып киткән гаиләләргә субсидия каралган. Агымдагы елда 70 меңнән артык гаилә әлеге төр ярдәмне ала. Ноябрьдә субсидиянең уртача күләме 1511 сум тәшкил иткән. Дәүләт ярдәмен рәсмиләштерү өчен, яшәү урыны буенча социаль яклау бүлекчәләренә мөрәҗәгать итәргә яки Дәүләт хезмәтләре порталы аша гариза җибәрергә кирәк. Ул ярты елга билгеләнә, аннары яңадан документлар тапшырасы булачак. Акчалата ярдәмгә муниципаль яки дәүләт торагында яшәүчеләр, наем килешүе нигезендә фатир алып торучылар, торак кооперативы әгъзалары, фатир, шәхси йорт хуҗалары дәгъва кыла ала. Тагын бер шарт – торакның мәйданы. Ул билгеләнгән стандартларга туры килергә тиеш. Әлеге күрсәткечне һәр төбәк үзе билгели. Татарстанда ул бер кешегә – 40 квадрат метр, ике кешелек гаиләдә җан башына – 23 квадрат метр, өч кешелек гаиләдә исә 17 квадрат метр тәшкил итә. Коммуналь түләүләр буенча бурычлары булганнарга субсидия бирелми.

– Халык өчен табигый газның ваклап сату хакы чималны күмәртәләп сату бәясе, аны транспортлау тарифлары һәм тәэмин итү-сату хезмәтләре өчен түләүләрдән чыгып билгеләнә. Аларны Монополиягә каршы федераль хезмәт раслый, – диде ул.

Җылылык кыш көне аеруча кадерле. Моны Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрының беренче урынбасары Алексей Фролов та әйтте.

– Бу атнада көннәр суыта, димәк, җылылык тагын да күбрәк тотылачак, – диде ул, алдагы айда киләчәк счет-фактура кәгазьләренең кыйммәтрәк булачагына ишарәләп. – Кышкы чорда болай да күп түлибез. Коммуналь түләү кәгазьләренә җылылык өчен шактый акча өстәлә. Бу кышта 2022 елның 1 декабрендә расланган тарифлар буенча исәп-хисап ясалачак. Шуңа күрә үзгәреш юк. Артык акча түләмәс өчен, өйдәге исәпләгечләрне карап-тикшереп торырга киңәш итәбез.

Форсаттан файдаланып, министрның беренче урынбасары республикада яңа елга кадәр газ килешүләрен яңарту тирәсендә килеп чыккан шау-шуга да ачыклык кертте.

Эш шунда ки, бу көннәрдә республиканың төрле шәһәрләре һәм районнарында яшәүчеләр арасында 2024 елның 1 гыйнварына кадәр газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтүгә бәйле килешүне яңадан төзергә кирәклеге турында хәбәрләр таралды. Анысы да монысы, яңа елга яңа гариза белән кермәүчеләрне 40 меңнән 100 мең сумга кадәр штраф белән куркыталар, дип хәбәр итә укучыларыбыз. Шуңа күрә республика районнарындагы газ оешмаларында озын чиратлар хасил булган.

Ахыры 2 нче биттә >

## Кунак әйбәтне сайлый

Быел гыйнвар – октябрь чорында, узган елның шул вакыты белән чагыштырганда, республикага килүче туристлар саны 9,3 меңгә арткан. «Реальное время» хәбәренә караганда, Татарстанда барлыгы 3371087 кеше кунак булып киткән.

2023 елның 9 ае йомгаклары буенча Татарстан туристлар саны ягыннан Идел буе федераль округында беренче урынны алган. Түбән Новгород өлкәсе (2013461 кеше) – икенче, Башкортстан (1942980) – өченче урында.

Сүз уңаеннан, Казан мэры Илсур Метшин белгечләрнең исәп-хисабына таянып әйткәнчә, М12 түләүле юлын ачу Татарстан башкаласына өстәмә рәвештә 1 миллион туристны җәлеп итәргә мөмкин.

## *Юлда йөрү кыйммәтләнә*

Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты җәмәгать транспортында юл бәясен 42 сумга җиткерергә ниятли. Комитет рәисе Александр Груничев әйтүенчә, бу мәсьәлә җомга – 8 декабрьдә каралачак.

Аның сүзләренә караганда, юл бәясен «тере» акча белән түләгәндә – 42 сумга, карта белән түләгәндә 38 сумга кадәр күтәрү тәкъдим ителә. Ләкин бу саннар үзгәрергә дә мөмкин.

Исегезгә төшерәбез: хәзер республика башкаласында җәмәгать транспортында йөрү хакы «тере» акча белән түләүчеләргә – 36 сумга, банк яки транспорт картасы белән түләүчеләргә 35 сумга төшә.

Шулай ук Чаллы һәм Түбән Камада да транспортта йөрү бәясе үзгәрергә мөмкин.

## Орлыгы нинди, урманы шундый

Татарстан урманнары өчен 12,7 тонна агач орлыгы әзерләгәннәр. Шуның 467 кг – нарат, 231 кг – чыршы, 15 кг – карагай, 454 кг – каен, 176 кг – юкә, 1,4 тонна – корыч-агач (ясень) һәм 10 тоннасы – имән орлыгы. Орлык җыю эше «Экология» илкүләм проектының «Урманнарны саклау» федераль проекты кысасында башкарылган.

Урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров әйтүенчә, быел орлык әзерләү планы 1,3 тоннага арттырып үтәлгән. Орлыклар урманнардан, махсус урыннарда орлыкка калдырылган агачлардан җыеп алынган. «Урманнарны торгызуның нәтиҗәсе орлык сыйфатына турыдан-туры бәйле. Шуңа күрә Татарстанда бу эшкә зур игътибар бирелә. Барлык орлыклар Урманнарны саклау үзәгендә тикшерелеп, аларга сыйфат сертификатлары бирелә», – ди министр.

Орлык җыю буенча Кәләй, Кайбыч, Буа, Минзәлә урман хуҗалыклары белгечләре алдынгылыкка чыккан.

Әйтергә кирәк, орлык җыю – «Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проектының өстәмә күрсәткече. Быел урманчыларга кимендә 11,4 тонна орлык әзерләү бурычы куелган булган.

## *Суыкта укымыйлар*

Татарстанда, кинәт суыту сәбәпле, синоптиклар кисәтү игълан итте. Шуны истә тотып, Мәгариф һәм фән министрлыгы ничә градуста мәктәптә дәресләрнең уздырылмаска мөмкин икәнлеген аңлатты.

Шулай итеп, авыл мәктәпләрендә башлангыч сыйныфларда укучыларга термометрның терекөмеш баганасы –23 градуска кадәр төшкән очракта дәрескә бармаска рөхсәт ителә. –25 градус суыкта исә шәһәр мәктәпләрендә – башлангыч сыйныфларда һәм авыл мәктәпләрендә – 5–9 нчы сыйныфларда укучылар гыйлем йортына бармаска мөмкин.

Температура –27 градуска кадәр төшсә, шәһәр мәктәпләренең дә 5–9 нчы сыйныфларында укучылар өйләрендә кала. –30 градуска кадәр суытса, авыл мәктәпләренең 10, 11 нче сыйныф укучылары дәресләрдән азат ителә. Шәһәр мәктәпләрендә исә өлкән сыйныф укучылары –32 градус суыкта гына мәктәпкә бармый.

Ачык һавада физкультура дәресләренә килсәк, башлангыч сыйныф укучылары өчен һава температурасының –3 градустан түбән булмавы, җил тизлегенең секундына 6–10 метрдан артыграк булмавы кирәк. Өлкән сыйныфтагылар өчен температура күп дигәндә –10 градус, җил тизлеге секундына 6–10 метр булырга тиеш.

**Спорт кына түгел бу!**

# Кил, күр!

## КАЗАН «КИЛӘЧӘК УЕННАРЫ»НА ӘЗЕР

**Тупмы, компьютермы? Хәзер инде кайсын сайлыйм дип баш ватасы юк. «Киләчәк уеннары» халыкара турнирында чынбарлык һәм виртуаль дөньяны берләштерәчәкләр. Спортчылар әзерләнә, ә Казан инде әзер. Тарих һәм Татарстан башкаласы өчен тәүге булган әлеге ярышлардан нәрсә көтәргә?**

«Киләчәк уеннары» турниры җитәкчесе Игорь Столяров киләсе елда Казанда узачак чараның максат-бурычлары турында сөйләде.

– Безнең проект танылу алды һәм бу танылу арта гына бара. Ярышларга 100 көн кала чара уздыру, уеннарның трофеен галәмгә җибәрү, дисеңме. Безгә бу хакта сөйләү дә бик рәхәт. Без турнирны матур итеп күрсәтергә омтылдык һәм омтылабыз. Бу чара матур булып күренсен өчен, бик күп көч түктек һәм матди мөмкинлекләр кулландык, – диде ул.

Игорь Столяров искәрткәнчә, уеннарның төп идеологиясе – кешенең рухи һәм физик яктан гармонияле үсеше.

– Без моны спорт аша һәм аны виртуаль дөнья белән кушу бәрабәренә күрсәтәбез. Фиджитал-спорт танылу алды, Россия күләмендә чемпионатлар уза, дөнья күләмендә дә узар дип өметләнәбез, – диде ул.

«Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» оешмасы генераль директоры Михаил Леонов әйтүенчә, ярышлардан тыш, турнир катнашучыларын һәм Казан кунакларын күңел ачу программасы да көтә. Кыш булса да, кызу булачак, ди оештыручылар.

Кыскасы, килмичә, күрмичә калырга ярамый. 2024 елның 21 февраленнән 3 мартына кадәр барысын да Казанда көтәләр. Президент та чакырды!



gofuture.games

**Уеннар турында санлы фактлар**
- **21** юнәлеш (дисциплина)
- **2000**нән артык спортчы
- **260** команда
- **100**дән артык катнашучы ил
- **11** спорт объекты
- **12** ярыш көне
- **400** сәгать трансляция

**Сүзгә-сүз**

**Ярослав НИЛОВ, Дәүләт Думасының Хезмәт, социаль сәясәт һәм ветераннар эше комитеты рәисе:**

Балигъ булмаганнарга сәнәгать өлкәсендә эшләргә рөхсәт итәргә кирәк. 17 яшьлек егетне мисалга алыйк. Аңа әле армиягә китәргә иртәрәк. Практика узган предприятиегә дә урнаша алмый, чөнки сәнәгать предприятиеләрендә 18 яше тулмаганнарны эшкә алмыйлар. Үсмерләргә аерым категория предприятиеләрдә эшләргә хокук бирүче төзәтмәләр кертергә кирәк.

**(«Парламентская газета»дан)**

## РОССИЯДӘ – ЭШ

**«Работа.ру» хезмәте Россиядә яшәүчеләрдән эш урынына бәйле сораштыру үткәргән. Сораштыруда катнашучыларның яртысыннан артыгы яңа елдан һөнәрен алмаштырырга, 57 проценты башка эш табарга әзер булуын әйткән.**



СӘБӘПЛӘРЕ

**83%** >> югары хезмәт хакы
**55%** >> яхшы коллектив һәм җитәкче
**38%** >> эш урынының яхшы урында урнашуы
**37%** >> уңайлы график



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

**Дөньяда**

## АЛТЫН КЫЙММӘТЛӘНӘ

Планета зур өч кризис давылында чайкала: финанс кризисы, демографик кризис, климат кризисы. Хәер, соңгысы турында бәхәсләшүчеләр байтак. Берәүләр бернинди климат үзгәрешләре дә юк дип санаса, икенчеләр, климат кризисы бар, әмма аның сәбәбе кеше эшчәнлегенә бәйләнмәгән, дип раслый. Үткән атнада Дубайда БМО оештырган климатик конференциянең чираттагысы булып үтте. Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Милли нефть компаниясе президенты Солтан әл-Җәбер анда: «Казылма ягулыктан баш тарту климатның индустриаль чорга кадәргедән 1,5 градуска кадәр җылынуыннан котылырга булышуы турында бернинди фәнни мәгълүмат та юк. Сез кешелек дөньясын кире тау куышына куып кертмичә генә нефть һәм газдан баш тарта алмыйсыз», – дип чыгыш ясаса, Климат кризисы буенча консультатив төркем рәисе Дэвид Кинг, 2035 елдан да соңга калмыйча, казылма ягулыктан баш тартырга кирәклеген расларга тырышты.

Финанс кризисы турында бәхәсләшүчеләр юк диярлек, чөнки дөнья глобаль әҗәтләр тавы астында калды һәм бурычларның түләнәчәгенә бернинди дә өмет юк. АКШның дәүләт әҗәтләрен түләү чыгымнары Пентагон бюджетын узып китте. Башка дәүләтләр арасында да дәүләт әҗәтен дә, тышкы бурычларын да түли алмаучылар саны үсә. Финанс пирамидасының кайчан булса да җимереләчәгенә шикләнүчеләр юк диярлек. Зур мәтәлчек алдыннан илләр үзләренең алтын запасын үстерергә омтыла. Барлык милли валюталар да алтын янәшәсендә очсызланалар. Икътисадый һәм геосәяси тотрыксызлык шартларында алтын бердәнбер ышанычлы актив булып санала. Хәтта АКШның Федераль резерв системасы алтын резервларын арттырырга ниятли. Декабрь башында алтын тарихи рекорд куйды: унциясе 2150 доллардан да кыйммәтрәк йөри башлады. CNBC телеканалы алтын бәясенең инде икенче ай рәттән үсүен әйтә. Моңа ике сәбәп бар, ди: Израиль белән ХАМАС арасындагы сугыш һәм процент ставкаларының төшерелүен көтү. Аналитиклар, 2024 елда да алтын бәясе унциягә 2000 доллардан кыйммәтрәк йөрер, диләр.

Чагыштырыгыз: 2015 елның 1 декабрендә алтын унциясе 1049 доллар белән бәяләнгән. 2000 нче еллар башында бер унция сары металлга 200–270 доллар гына биргәннәр. Беренче тапкыр алтын 2008 елның мартында каты сикергән: бәясе 1032 долларга җиткән. Алтын бәясенең соңгы егерме елдагы графигына карасак, без озак сроклы перспективада кәгазь валюталарның никадәр ышанычсыз булуын күрә алабыз. Бигрәк тә хәзерге – иртәгәсе көнгә ышаныч беткән шомлы заманда алтын һәм көмеш мал саклауның иң ышанычлы чарасына әйләнәләр.

**Россиядә**

## ХЕЗМӘТ ХАКЛАРЫ УЗЫШТАН ТУКТЫЙ

Bloomberg Economics, Россия икътисады үзенең үсеш мөмкинлекләрен файдаланып бетерде, дип саный. Көнбатыш белгечләренә ышансак, 2024 елның III кварталында үсеш темплары 0 процентка калачак, ә IV кварталда тискәре якка китәчәк. Моның сәбәбе итеп төп ставканың июньдәге 7,5 проценттан 15 процентка кадәр күтәрелүен күрсәтәләр. Кредитлау кимер, диләр. Төп ставканың әле тагын да күтәрелү ихтималлыгы зур булуын искә алсак, Bloomberg фаразлары тормышка ашарга да мөмкин. Чит ил белгечләре оборона тармагы һәм эшкәртү предприятиеләре үзләрен яхшырак хис итәр дип саный.

Россиянең үз белгечләре, киләсе елда хезмәт хакларының быелгы кебек узышы булмаячак, дигән фикер әйтә. Бизнесның ресурслары бетә, ди алар. Сентябрьдә инде реаль хезмәт хаклары үсеше темпы 7,2 процентка калган, августта ул 9,5 процент булган. Номиналь хезмәт хаклары сентябрьдә, еллыкка күчереп исәпләгәч, 13,6 процент кына булган. Августта ул сан 15,1 процентка тигез. Реаль хезмәт хакы номиналь хезмәт хакыннан инфляцияне алып ташлап исәпләнә. Бәйсез белгечләр реаль инфляция темплары рәсми инфляциядән ике тапкыр күбрәк дип саный. Алар күзлегеннән карасак, реаль хезмәт хакы үсеше бик сизелми дә әле.

Икътисадый үсеш министрлыгында 2024–2026 елларда номиналь хезмәт хаклары үсеше – 7,7 процент, ә реаль хезмәт хакы үсеше 2,5 процент тәшкил итәр дип исәплиләр. Инфляция Үзәк банк фаразлаган кысада булса инде. Әмма акча ел саен рәсми фаразга караганда күбрәк очсызлана.

Белгечләр әйтүенчә, югары квалификацияле эшчеләргә мохтаҗ булган предприятиеләр аларны тиз генә әзерли алмыйлар. Шуңа күрә аларны югары хезмәт хаклары белән кызыктырып «ау»ларга туры килде, ягъни квалификациягә ия булучылар, түбән хезмәт хакы түләнә торган урыннарны ташлап, күбрәк түләүчеләргә китте. Нигездә оборона заказын үтәүчеләргә күчү барды. Бу юл белән эшчеләр аулаганда, хезмәт җитештерүчәнлеге үсми, чөнки аның өчен модернизация кирәк, инвестицияләр таләп ителә. Шул сәбәпле окладлар арттыру процессы түбәгә төртелә һәм төгәлләнә. Белгечләр: «Һәрвакытта да кредит бәясе белән хезмәт хакы үсеше үзара бәйлелектә тора. Кредит кыйммәтләнгәндә, хезмәт хакын киметү үзкыйммәтне киметүнең бердәнбер юлы булып кала, комплектлаучы детальләр бәясенә йогынты ясый алмыйлар бит», – диләр.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

# БУАГА – БҮЛӘК

tatarstan.ru

**Буада – тантана. Районда төзекләндерүдән соң театр бинасы ачылды. Сәнгать йортына хәер-фатихасын Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та бирде.**

Билгеле булганча, Буа дәүләт драма театрының бинасын 2022 елның язында төзекләндерә башлаганнар иде. Яңартылган бинада профессиональ артистлар һәм музыкаль коллектив чыгышлары һәм репетицияләре өчен барлык шартлар да тудырылган. Моннан тыш, бинаның гомуми мәйданы 4 мең квадрат метрга кадәр артты. Залга 400дән артык кеше сыя.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Буа театрының республика халыклары сәнгатен алга сөрүдә мөһим роль уйнавын билгеләп үтте.

– Биредә искиткеч коллектив, бик көчле җитәкче, – дип мактау сүзләре дә ирештерде Рәис. – Иң мөһиме – моның белән генә чикләнмисез. Сез Россия төбәкләре буйлап гастрольдә йөрисез, башка илләргә дә чыгасыз. Бу – бик зур, мөһим эш. Андый эш башка илләрдәге ватандашларыбыз белән элемтәләрне ныгыту кысасында да алып барыла.

Яңа бина замана таләпләренә туры килә, дидек инде. Рөстәм Миңнеханов та: «Бу бинаның кешеләрне җәлеп итә торган яңа үзәккә әвереләсенә ышанам», – диде. Рәис сүзләренә караганда, бу урын Буа тамашачысы белән генә чикләнмәс.

> Башка районнар өчен дә кирәкле урын. Сезнең янәшәдә генә – Ульяновск өлкәсе. Театрның эчтәлеге сыйфатлы булырга тиеш. Шул ук вакытта тамашалар татар телендә генә бармасын. Чөнки биредә бик күп руслар, чуашлар, башка милләт вәкилләре яши. Татарстан – күпмилләтле республика, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Бина ачылышында катнашкан мәдәният министры Ирада Әюпова әйтүенчә, Буадагы театрны «Мәдәният» илкүләм проекты кысасында кулланышка тапшырганнар. Сүз уңаеннан, бу – федераль бюджет хисабына сафка баскан дүртенче театр.

Буа районы башлыгы Ранис Камәртдинов та театр ачылышын тарихи вакыйга дип телгә алды.

– Безнең өчен тарихи әһәмияткә ия вакыйга. Барыбыз да яраткан театрның яңа бинасы – безгә һәм бөтен республика халкына зур бүләк, – диде ул.

**Дәүләт Советында**

# *Гадел булсын*

**Бүген җәмәгать юстициясе, кеше хокуклары һәм ирекләрен яклауны камилләштерүгә зур өлеш кертеп, Россиядә суд хакимияте абруен булдыруда төп урын алып тора. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин республиканың төрле районнарындагы суд участокларына сайланган җәмәгать судьяларына таныклык тапшырганда шулай диде.**

Ул 18 җәмәгать судьясына хезмәт таныклыклары тапшырды. Парламент башлыгы, судьяларны җаваплы вазыйфага сайланулары белән котлап, судьяларның гамәлләре һәм карарларының гадел булырга тиешлеген әйтте. Аның сүзләренә караганда, хәзерге вакытта Татарстанда 190 җәмәгать судьясы эшли. Узган елда җәмәгать судьялары 760 меңнән артыграк эшне караган.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, эшчәнлекне цифрлаштыру республика суд системасының төп бурычларының берсе булып кала. Хәзерге вакытта республикада цифрлы инфраструктура һәм электрон сервислар булдыру буенча зур эш алып барыла. Җәмәгать судьяларының барлык суд участокларында суд приставлары хезмәте белән электрон хезмәттәшлек булдырылган.

# Яңа кышта – иске бәя

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– 2024 елның 1 гыйнварына кадәр газ килешүен төзергә өлгермәүчеләр «зәңгәр ягулык»сыз калмаячак, – дип тынычландырды Алексей Фролов. – Ил күләмендә йорттагы газ челтәрләреннән файдалануга бәйле килешүләрне бер оешмага тапшыру турында карар кабул ителде. Тагын бер кат искәртәм: бу – федераль дәрәҗәдәге эш. Татарстанда моның белән «Таттрансгаз» шөгыльләнәчәк. 2024 елның 1 гыйнварына кадәр идарәче оешмалар килешүләрне яңартырга тиеш. Ни кызганыч, республиканың кайбер районнарында «Таттрансгаз» инде хәзердән үк милек хуҗалары белән дә яңа килешүләр төзи башлаган. Нәтиҗәдә аңлашылмаучанлык килеп чыккан. Физик затларга яңа елга кадәр яңа документ алу мәҗбүри түгел. Моны алга таба да эшләргә мөмкин. Моңа карап кына беркем дә газсыз калмаячак.

Министрның беренче урынбасары әлеге мәсьәлә тирәсендә туган шаушуны урынсыз дип атады.

– Бернинди ыгы-зыгы булырга тиеш түгел. Мин физик затлар белән килешүләрне яңартуга бәйле бернинди кыенлык та күрмим. Аны ел дәвамында хәл итәчәкбез. Милекчеләргә штраф салу турында сүз дә юк. «Таттрансгаз»ның кайбер бүлекчәләре, берьюлы ике эшне башкармакчы булып, таякны артык бөгеп ташлаган, шул гына, – диде ул.

Яңа елга тыныч күңел белән керә аласыз!

Эльвира ВӘЛИЕВА

**Сан**

2024 елның 1 июленнән ут өчен бер ставкалы тариф **41 тиен**гә артачак һәм бер кВт/сәгате 5,09 сумга җитәчәк. Электр плитәләре белән җиһазландырылган шәһәр йортларында бер ставкалы тариф, **52 тиен**гә кыйммәтләнеп, бер кВт/сәгате 4,10 тиен тәшкил итәчәк. Авылда яшәүчеләр өчен ул, **29 тиен**гә артып, бер кВт/сәгате 3,57 сум булачак. Газ бәясе **76 тиен**гә артачак.

(Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетыннан).

# ҖИДЕ ТҮГЕЛ, ҖИТМЕШ ҮЛЧИСЕ

**Олысын да, кечесен дә сакларга! Бөтендөнья тәмәкегә каршы көрәш көне уңаеннан җыелган бер төркем белгеч әнә шул фикерне кабатлады. Гадәти тәмәкенең зыяны турында сөйләшүдән башланган очрашу үзеннән-үзе электрон тәмәке, вейпларның зыянына барып тоташты. Бүгенге шартларда башкача була да алмый кебек.**

Ун ел элек Россиядә яшәүчеләрнең 60 проценты тәмәке тарткан. Хәзер бу сан 40 процентны тәшкил итә. Әмма бу саннарга сөенергә иртәрәк, ди белгечләр. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш балалар психиатр-наркологы Степан Криницкий сүзләренә караганда, әлеге саннар, бердән, халык арасында уздырылган сораштыру барышында гына алынган. Чынлыкта вазгыять башкача булырга мөмкин. Ник дигәндә, бүген илдә тәмәке тартучы-тартмаучыларның төгәл статистикасы алып барылмый. Аннары электрон тәмәке пәйда булу белән Россиядәге тәмәке тартучыларның күбесе вейпларга күчкән. Саннарның кимүе шуның белән дә аңлатылырга мөмкин.

– Әле кайчан гына тәмәкегә бәйлелек турында сөйли идек, хәзер инде никотинга бәйлелеккә каршы көрәшәбез. Тәмәкегә бернинди катнашуы булмаган вейп, кальян кебек заманча уенчыклар пәйда булу белән шулай килеп чыкты бу. Бүген электрон тәмәке без белгәне белән чагыштырганда күпкә зарарсызрак дигән фикер яши. Күпләр хәтта аның ярдәмендә тартуын да ташламакчы була. Әмма бу – ялгыш фикер.

> **Электрон тәмәке тартканда кеше организмына гадәти тәмәке белән чагыштырганда 20 тапкыр күбрәк (!) никотин керә. Алар үпкә, кан әйләнеше системасына шулай ук зур зыян сала.**

Тәмәке тартуны ташлау кыен, никотинга бәйлелектән арыну тагын да кыенрак. Өстәвенә бу «уенчык» шартларга, аның эчендәге сыекчадан агуланырга да мөмкин, – диде Степан Криницкий журналистлар белән очрашуда.

Бүген кулыннан вейп төшермәгән күпләр бу хакта белми дә, белергә дә теләми кебек. Электрон көпшә көйрәтү баласына да, анасына да гадәти хәлгә әверелеп бара. Чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, пар белән төтенләргә яратучылар адым саен очрап торгач, үсмерләр, хәтта балалар да моны гадәти күренеш итеп кабул итә. Юкса бүген электрон тәмәкенең шәһәрдә генә түгел, чеп-чи татар авылы мәктәбендә укучы үсмерләр арасында да ныклап тамыр җәюен башкача ничек аңлатасың?

Беренче категорияле табиб-пульмонолог Татьяна Неешпапа моның тагын берничә сәбәбен атый.

– Бүген вазгыять коточкыч: электрон тәмәкене 11–12 яшьлек балалар да тарта. Алар балаларны, нигездә, аллы-гөлле матур кабы, хуш исе белән җәлеп итә. Шул ук ис бу кырын эшне ата-анага сиздермичә генә эшләргә ярдәм итә. Зур булмагач, аларны җайлы гына яшереп тә була, – ди белгеч.

Гадәти тәмәке кебек, электрон тәмәкенең дә, иң беренче чиратта, үпкәләргә зыян салуы көн кебек ачык. Татьяна Неешпапа сүзләренә караганда, электрон тәмәке гадәти тәмәке кебек үк хроник үпкә авырулары китереп чыгара. Вейплар белән мавыккан кешенең иң элек сулыш алуы кыенлаша. Рәсми рәвештә бу авыру ХОБЛ дип атала. Үлем-китем очракларына китергән чирләр исемлегендә яман шеш һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан соң өченче урында ул. ХОБЛ белән авырган кеше ахыр чиктә булыгып үләргә мөмкин.

– Моннан тыш электрон тәмәке бронхиаль астма да китереп чыгара ала. Вейп тартучы янында торган кеше үзе дә автомат рәвештә пассив тәмәке тартучыга әверелә. Шуңа күрә баласы янында электрон тәмәке тарткан ата-ана аның организмын да зарарлый, – ди пульмонолог. – 2019 елдан дөньяда тәмәке тарту аркасында ясалган үпкә җәрәхәте дигән төшенчә гамәлгә керде. Бүген күпләргә әнә шундый диагноз куела. Андый чакта кешене көчле ютәл борчый, ул буыла, томография узганда үпкә тукымасының шактый зарарланган булуы ачыклана. Әлеге үпкә авыруы ашказаны-эчәк системасы эшчәнлегенә дә тискәре йогынты ясарга мөмкин.

Татьяна Неешпапа сүзләренә караганда, тәмәке, вейп тарткан кеше иң беренче чиратта берөзлексез йөткерә башлый икән. Әлеге начар гадәт белән мавыккан үсмерләрне «сата» торган иң төп билге дә әнә шул. Ата-анага иң элек шуңа игътибар итәргә куша белгеч.

Журналистлар белән очрашуда чәчләр үрә торырлык тагын бер сан яңгырады. Ел саен Татарстанда 1,6 меңләп кешегә үпкә яман шеше диагнозы куела. Республика клиник онкология диспансерының 1 нче номерлы торакаль бүлеге җитәкчесе Артур Гыйльметдинов сүзләренә караганда, моңа күбрәк һаман да шул тәмәке, вейп тарту кебек начар гадәтләр сәбәпче.

– Тәмәке тарту үпкәдә генә түгел, йоткылык, авыз эче, тел, ашказаны, ашказаны асты бизендә дә яман шеш китереп чыгарырга мөмкин. Араларында иң киң таралганы – үпкә яман шеше. Татарстанда елына 1,6 меңләп кешегә әнә шундый диагноз куела. Шуларның өчтән бере беренче-икенче стадиядә ачыклана, – ди белгеч.

Гадәти тәмәке белән электрон тәмәке икесе дә авыз куышлыгына да зур зыян сала. Казан шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенең штаттан тыш белгече, стоматолог Ләйсән Моратова сүзләренә караганда, һәр ике очракта да авыз куышлыгы нык зарарлана.

– Тәмәке тарткан кешенең теш эмале саргая, ярыла, авызыннан авыр ис килә. Электрон тәмәке тешнең эмален саргайтмаса да, авыш куышлыгының лайлалы тышчасын яндыра. Монысы тагын да хәтәррәк. Кызганыч, соңгы арада яшьләр арасында авыз куышлыгы яман шеше күпләп очрый башлады. Шуңа күрә яшьләр теләсә нәрсә тартыр алдыннан сәламәтлеге, киләчәге турында уйлансын иде. Бу юнәлештә көтелгән нәтиҗә булсын өчен, мәктәпләрдә электрон тәмәке тартуның ни дәрәҗәдә зыянлы булуын, аның нәрсәгә китерүен аңлаткан дәресләр дә уздырырга кирәк, – ди белгеч.

Хәер, бүген мондый сабакны балаларга гына түгел, олыларга укытсаң да артык булмас иде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $31^{1.2}$ статьясындагы 3 пунктының, 32 статьясындагы 3 пунктының (чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасы өлешендә), $32^{1}$ статьясындагы 3 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш) гамәлдә булуын 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**2 статья**

1. Геосәяси һәм икътисадый вәзгыять начарлануның икътисад тармаклары үсешенә йогынтысын булдырмый калуга бәйле чараларны һәм, аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтүне дә кертеп, милли оборона һәм милли иминлек өлкәсендәге өстәмә чараларны финанс белән тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләренә 2025 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясындагы 3 пункты нигезләмәләре кагылмый дип билгеләргә.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) кытлыгы Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында (муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле бюджет турындагы муниципаль хокукый актында) билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) кытлыгы күләменнән һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 24 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән чикләүләрдән геосәяси һәм икътисадый вәзгыять начарлануның икътисад тармаклары үсешенә йогынтысын булдырмый калуга бәйле чараларны һәм, аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтүне дә кертеп, милли оборона һәм милли иминлек өлкәсендәге өстәмә чараларны финанс белән тәэмин итү өчен җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре суммасына артыграк булырга мөмкин дип билгеләргә.

3. 2024 елда Татарстан Республикасы дәүләт бурычының (муниципаль бурычның) күләме Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында (муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле бюджет турындагы муниципаль хокукый актында) билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт бурычының (муниципаль бурычның) югары чигеннән, шул исәптән эчке дәүләт хисаплашулары программасы күрсәткечләреннән, геосәяси һәм икътисадый вәзгыять начарлануның икътисад тармаклары үсешенә йогынтысын булдырмый калуга бәйле чараларны һәм, аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтүне дә кертеп, милли оборона һәм милли иминлек өлкәсендәге өстәмә чараларны финанс белән тәэмин итү өчен җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре күләменнән артыграк булмаган суммага артыграк булырга мөмкин дип билгеләргә.

4. 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетын (җирле бюджетны) үтәү барышында Татарстан Республикасы бюджетының (җирле бюджетның) җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертү өчен Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән нигезләргә өстәмә рәвештә, геосәяси һәм икътисадый вәзгыять начарлануның икътисад тармаклары үсешенә йогынтысын булдырмый калуга бәйле чараларны һәм, аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтүне дә кертеп, милли оборона һәм милли иминлек өлкәсендәге өстәмә чараларны финанс белән тәэмин итүгә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (җирле администрация) тарафыннан билгеләнгән башка максатларга җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре яңадан бүленгән очракта, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) кытлыгын финанслау чыганаклары төрләре арасында бюджет ассигнованиеләре яңадан бүленгән очракта, Татарстан Республикасы бюджетының (җирле бюджетның) җыелма бюджет язмасына, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына (муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле бюджет турындагы муниципаль хокукый актына) үзгәрешләр кертмичә генә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (җирле администрация) карарлары нигезендә үзгәрешләр кертелергә мөмкин дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы бюджетының (җирле бюджетның) җыелма бюджет язмасына әлеге статьяның 4 өлешендә билгеләнгән нигезләр буенча үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында (муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле бюджет турындагы муниципаль хокукый актында) расланган чыгымнарның гомуми күләмен арттырып гамәлгә ашырылырга мөмкин дип билгеләргә.

6. 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетын (җирле бюджетны) үтәү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында (муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле бюджет турындагы муниципаль хокукый актында) билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) кытлыгының күләме геосәяси һәм икътисадый вәзгыять начарлануның икътисад тармаклары үсешенә йогынтысын булдырмый калуга бәйле чараларны һәм, аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтүне дә кертеп, милли оборона һәм милли иминлек өлкәсендәге өстәмә чараларны финанс белән тәэмин итү өчен җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре суммасына арттырылырга мөмкин дип билгеләргә.

7. Әлеге статьяның 4 өлешендә, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3 һәм $3^{2}$ пунктларында каралган карарларга һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы $3^{1}$ пунктында каралган нигезләргә таянып Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларыннан бирелә торган акчаларга һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына тиешле бюджет турындагы законда (карарда) расланган бюджет ассигнованиеләре составында резервланган акчаларга 2025 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $20^{1.3}$ статьясындагы 2 пунктының беренче абзацы, 21 статьясындагы 2 пункты, $44^{4}$ статьясындагы 4 пунктының бишенче абзацы, $44^{5}$ статьясындагы 4 пунктының беренче абзацы һәм $4^{2}$ пунктының беренче абзацы, $44^{6}$ статьясындагы 10 пункты нигезләмәләре кагылмый дип билгеләргә.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәгәндә Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезләмәләре «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $96^{6}$ һәм $220^{1}$ статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып кулланыла.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 04 декабрь
№ 118-ТРЗ

## «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 2 өлешендә «Адвокатлар» сүзеннән соң «һәм нотариуслар» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $11^{1}$ статья өстәргә:

«$11^{1}$ статья. **Нотариуслар тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү**

1. Нотариуслар Федераль законда һәм әлеге Законда каралган очракларда һәм тәртиптә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтә.

2. Татарстан Республикасында дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы эшчәнлегендә нотариусларның катнашуын оештыру Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы тарафыннан башкарыла.

3. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында нотариуслар тарафыннан түләүсез кылынган нотариаль гамәлләр өчен түләүне компенсацияләү Федераль законда билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3) 12 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасы өстәргә:

«д) ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның варислык хокукларын яклау турында;»;

4) 18 статьяның 2 өлешендә «компенсацияләүгә» сүзеннән соң «, дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында нотариуслар тарафыннан түләүсез кылынган нотариаль гамәлләр өчен түләүне компенсацияләүгә» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 04 декабрь
№ 119-ТРЗ

## «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 2 пунктта «урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен» сүзләрен «федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктта «урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен» сүзләрен «федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $6^{2}$ һәм $6^{3}$ пунктлар өстәргә:

«$6^{2}$) Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән килештереп раслау;

$6^{3}$) ашыгыч чаралар күрүне куллану турында федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы карарын килештерү;»;

2) 3 статьяның 3 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^{1}$ һәм $1^{2}$ пунктлар өстәргә:

«$1^{1}$) Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын эшләү;

$1^{2}$) урманчылык территориясендә урманнарны янгынга каршы төзекләндерү планын эшләү һәм раслау;»;

б) $13^{9}$ пунктта «янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыру һәм урман янгыннарын сүндерү» сүзләрен «урман янгыннарын контрольдә тоту зоналарын билгеләү, урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларын башкару, урман янгыннарын сүндерү» сүзләренә алмаштырырга, «урман янгыннарын сүндерү максатларында» сүзләрен «урман янгыннарын сүндерү, шулай ук ашыгыч чаралар күрүне гамәлгә ашыру максатларында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен торглар үткәрмичә урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү тәртибе**

1. Гражданнар үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләүне гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен торглар үткәрмичә урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе (алга таба – үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе) нигезендә башкаралар.

2. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзергә теләгән граждан (алга таба – гариза бирүче) вәкаләтле органга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында гариза (алга таба – гариза) белән мөрәҗәгать итә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлү турында белешмәләр, шәхесен таныклый торган документ белешмәләре;

2) чикләрендә урман утыртмаларын сату-алу күздә тотыла торган урманчылык исеме;

3) агачның таләп ителә торган күләме, аның сыйфат күрсәткечләре һәм аны әзерләү максаты.

3. Гариза язма рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша яисә, «Дәүләт хезмәтләре (функцияләре) һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин.

4. Гариза алган көннән алып 10 көн эчендә вәкаләтле орган гариза бирүче белән үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзи яисә мондый шартнамә төзүдән баш тарту турында, гариза бирүчегә бу хакта гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итеп, карар кабул итә. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хәбәрнамәдә мондый баш тартуның сәбәбе күрсәтелергә тиеш.

5. Вәкаләтле орган үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарны түбәндәге очракларда кабул итә:

1) тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат булган документлар тәкъдим ителсә;

2) агачның гаризада күрсәтелгән күләме әлеге Законның 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән нормативлардан артып китсә;

3) гариза бирүче күрсәткән урманчылыкта гаризада күрсәтелгән таләп ителә торган сыйфат күрсәткечләренә ия агач күләмнәрен әзерләү өчен җитәрлек урман утыртмалары булмаса;

4) әлеге Законның 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән сроклар үтәлмәсә.

6. Чикләрендә гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләүгә яраклы урман утыртмалары урнашкан урманчылыклар турында мәгълүмат вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 2 пунктлары 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 04 декабрь
№ 120-ТРЗ

## Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә кабул ителде

**1 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының $28^{3}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), 48 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**2 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясындагы 21 пунктына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**3 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $46^{1}$ статьясына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**4 статья**

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы егерме өченче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (I өлеш); 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 12 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 51 (I өлеш), «социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**5 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $9^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**6 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $16^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**7 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $3^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 51 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**8 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $6^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**9 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $17^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**10 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $5^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 86 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**11 статья**

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $5^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**12 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының $28^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**13 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $25^{2}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**14 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $5^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

**15 статья**

«Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясындагы $2^{1}$ өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**16 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 04 декабрь
№ 121-ТРЗ

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә һәм транспорт комплексына квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүләре өчен «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсенең Чистай техник мәктәбе» һөнәри белем бирү учреждениесе башлыгы **Дәүләтшин** Әсхәт Габсамат улы, «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсенең Кукмара автомобиль мәктәбе» һөнәри белем бирү учреждениесе башлыгы **Фәйзрахманов** Рафаэль Саттар улы; эшләрендә ирешкән уңышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлештәге чараларны үстерү һәм аларга булышлык итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы персонал белән эшләү бүлегенең кадрларга бәйле документлар буенча әйдәүче белгече **Закирова** Венера Җәмил кызы, «Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлештәге чараларны үстерү һәм аларга булышлык итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасының куркынычсызлык хезмәте җитәкчесе **Мөхәммәтҗанов** Александр Әнвәр улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Милләтләр арасында татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга, татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен Пенза өлкәсенең «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе **Васильева** Эльмира Хәмзә кызы, Чиләбе өлкәсе татар конгрессы өлкә иҗтимагый оешмасы Башкарма комитеты әгъзасы **Гыйбадуллин** Равил Хәмит улы; Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы «Урман янгыннарын сүндерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең урман янгыннарын сүндерү станциясе тракторчы-машинисты **Галәүтдинов** Габбас Абдулла улы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Документлар белән тәэмин итү идарәсе редакторлар экспертизасы һәм тәрҗемәләр бүлеге баш белгече **Голова** Людмила Николаевна, «Әлмәтнең «Көньяк-Көнчыгыш» тернәкләндерү-производство предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Кузнецов** Валерий Александрович, «Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концерт залы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе реклама һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенең реклама буенча менеджеры **Рафикова** Зөлфирә Вагыйзь кызы, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең икътисад һәм предприятиегә идарә кафедрасы доценты **Сәлимов** Радий Илдус улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең биналарга комплекслы хезмәт күрсәтүче һәм төзекләндерүче эшчесе **Калашникова** Анна Степановнага, «ПАРК-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Мурзов** Сергей Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Казан шәһәренең «Ракета» физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тренеры-укытучысы **Исмәгыйлев** Айрат Минһади улына, Казан шәһәренең «Тасма» физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесенең дзюдо бүлекчәсе тренеры-укытучысы **Ходайбиргәнова** Анжелика Евгеньевнага, Казан шәһәренең «Идел» физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тренеры **Царев** Павел Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

## ӨЧ БАЛАСЫН КӨТҮЧЕ АНА:
# «МИҢА АЛАР ҮЗЛӘРЕ КИРӘК!»

**Өмет**

**Арча районының Курса разъездында яшәүче Гөлфирә Каюмова 13 бала табып үстергән. Беренче баласына – 39 яшь, иң кечесенә 19 тулган. 57 яшьлек Гөлфирә апаның тугыз малае, 4 кызы бар. Бүген өч улы – махсус хәрби операция зонасында, тагын ике улының армиягә китәр вакыты җиткән. Әниләренең өзгәләнүен күреп, әлегә аларны алмый торалар.**

– Хәзер менә күз алдына китереп ятам. Ул кадәр баланы ничек таптым икән, дим. Нинди йөрәкле булганмындыр инде... – ди Гөлфирә апа. – Ирем, төшермисең, диде, мин табып бардым. 14 иде минем сабыйларым. Унынчысы тугач та үлде. 1984 елдан 1993 елга кадәр туган 9 баламны әти-әнием караштты. Иремнекеләр кием-салым алып бирде. Юклык белән үстермәдем мин аларны, берсенең киемен икенчесе дә кия иде. Ә менә соңрак тапкан дүрт балама кешедән калган кием кидертмәдем.

Гөлфирә апа үзе дә ишле гаиләдән. Алар унау булалар. Шуңа да күп бала үстерү кыен булмый аңа. Яшерми, төрле чаклар булган. Хәзерге кебек керне – машина, идәнне робот юмаган. 13 баланы ашатырга да кирәк бит әле. «Таң алдыннан су ташыдым, табак-табак кабартма пешердем, ишегалды тулы мал-туар, кош-корт иде. Өйдәге эшне тәртипләп, балаларны бакчага илтеп, үзем дә Яңа Чүрилегә эшкә китә идем. 30 ел психоневрологик интернатта эшләдем», – ди Гөлфирә апа.

Ире Айдар урманчылыкта эшли. Кызганыч, кинәт авырый башлый. Табиблар яман шеш диагнозы куя. Гөлфирә апа, эшеннән китеп, ирен 8 ай тәрбияли. Тик чир җиңә, ике ел элек ире үлеп китә.

– Айдар гел ярдәм итеп торды. Ул кызу холыклы иде. Вакытында тормозына басмасаң, икешәр сәгать дулар иде. Шулай да аңлашып яшәдек. 39 ел бергә гомер иттек. Балаларның күбесе холкы белән әтиләренә охшаган. Әгәр Айдарым исән булса, миңа хәзер җиңелрәк булыр иде, – ди Гөлфирә апа.

Бүген аның өч улы махсус хәрби операция зонасында. Ана улларын өзелеп көтә. Өчесенең дә гаиләләре, балалары бар бит! Иң элек Илдары китә. Аннан – Ленар. Аның артыннан Илнары да, барам, ди.

– Игезәк ике улыма 38әр яшь бит инде. Шулкадәр өзгәләндем. Кайсы ана улын сугышка теләп җибәрсен инде?! Әтиләре холкы шул аларда, әйттеләрме, эшлиләр, – ди Гөлфирә апа.

Илдары бик каты яраланган. 20 көннән артык элемтәгә чыкмаган. Шул вакытта чәчләрем агарды, ди.

– Ике аягына да зыян килгән. Әлегә телефоннан сөйләшеп торабыз. Мәскәү госпиталендә ята. Хатыны янына барып кайтты инде. Тиздән мин дә янына барырга җыенам. «Әни, өчпочмакларыңны алып кил», – ди. Коймак та пешерермен. Түземсезлек белән очрашуны көтәм, – ди Гөлфирә апа. – Ленар белән Илнарым өчен бик өзгәләнәм. Көн туган саен нинди хәбәр килер икән дип көтәм. Телефон шалтырауга котым оча. Миңа балаларымның исәнлеге кирәк. Үз аякларында чыгып киттеләр, шулай ук кайтып та керсеннәр иде. Бала хәсрәтләре күрергә язмасын! Бармакның кайсын тешләсәң дә, авырта бит. Һәрберсен яратып үстердем. Миңа үзләреннән башка берни кирәкми!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

# БАТЫР МЫРАУЛАР

**Тычканнар тынгы бирми. Суыклар башланганнан бирле, хәрби операциядә катнашучы егетләрне әнә шул проблема борчый. Нурлат волонтерлары, кимерүчеләрдән коткару өчен, яуга мәчеләр җибәрә башлаган. Алар илне солдатлар белән бергәләп саклаячак!**

Нурлат районында яшәүчеләр хәрбиләргә болай да кирәк-ярак җибәреп тора. Шулай ук алар тычканнар белән көрәшкә дә битараф түгел. Кемдер капкын, махсус җилемнәр җибәрсә, «Легенда» хәрби-патриотик клуб җитәкчесе Владимир Малыгин бөтенләй башка чарасын тапкан.

Владимир Малыгин әйтүенчә, блиндажларда тычканнар бик күп. Аларга җилем ише әйберләр белән генә каршы торып булмый. Мәчедән башка берни дә булышмый. Тычканнар исә аның исеннән үк курка.

– Без әлегә унлап мәче җибәрдек. Тагын җыябыз. «Без дә бирер идек», – дип шалтыратучылар бар. Әлеге җан ияләре бер өй мохите тудыра. Мырлап торсалар да, җылылык өстәрләр. Әгәр песиләрегез булса, сез дә җибәрегез. Анда нәкъ менә авыл мәчеләре кирәк, – диде Владимир Малыгин.

Берничә ай элек Малыгиннарның мәчеләре балалаган. Үскәч, тычкан тота башлаган болар. Менә шуннан соң гаилә башлыгына, нигә хәрбиләргә ярдәм итмәскә, дигән фикер килгән дә инде. Мәчеләрне җыеп, «Газель»гә төяп җибәреп булмый бит әле. Илтү мәсьәләсен дә уйларга кирәк. Волонтер Айрат Гәрәев махсус тартмалар ясаган. Читлеккә аслык җәеп, ризыгын, тышка йөрер өчен чүлмәген куйган алар. Мәчеләр исән-имин генә фронтка барып җиткән инде. Әлбәттә, солдатлар Мырау батырларны сөенеп каршы алган.

«Легенда» хәрби-патриотик клубы хәрбиләр өчен гуманитар ярдәмне аз җыймый. Владимир Малыгинга өендәге генератор, бензин пычкысы да жәл түгел. Хатыны әнә 200 трусик теккән. Шәһәр халкы да хәрбиләргә ашау-эчү, эчке кием, җылы чалбар, оекбаш һәм башкасы белән булышып тора. Кукмара итек фабрикасы итекләр белән ярдәм иткән. Госпиталь өчен инвалид арбалары җибәргәннәр. Нурлат халкы җибәргән мичләр, шәмнәр хәрбиләрнең яшәү урынын, окопларны җылыта. Кыскасы, ярдәмне оештыра беләләр.

«Җиңү өчен тәм-том» волонтерлар төркеме хәрбиләргә азык-төлек әзерләп җибәрә. Шушы вакыт эчендә 109 мең өлеш (порция) аш җибәргән алар. 700 кило тозлы кәбестә, 2 мең кило ит, колбаса һәм башкасын. Моннан тыш, чәкчәк, печенье, кекс ише тәм-томы да бар.

Нурлат аграр техникумы мөгаллиме Халисә Хәйбуллованың улы Азат та, укыткан студентлары да хәрби операциядә катнаша икән. «Йоклап ятып булмый, хәлдән килгән кадәр булышырга кирәк», – ди ул. Шуңа күрә мөмкинлеге булган саен ярдәм итеп тора. Солдатларга 2,5 мең кап чәй төргәкләп озаткан. Моннан тыш эчке кием, мендәр тышлары, җәймәләр дә тегә.

– Узган елның октябрендә «Үзебезнекеләргә тегәбез» оешмасына барып, эчке киемнәр тегә башладым, – ди 61 яшьлек Халисә Хәйбуллова. – Җәй көне Якты Күл авылына кайткач, төрле үләннәр җыеп киптердем. Арада мәтрүшкә, бөтнек, карлыган, чия яфраклары, мелисса һәм башкасы да бар. Шулардан чәй ясадым. Улым кайткач, көчтәнәчкә дип биреп җибәргән идем, иптәшләре бик ошаткан. «Бигрәк тәмле, әниең безгә дә ясасын әле», – дигәннәр. Шуннан күпләп җибәрә башладым. Һәр пакетка «чәй җаннарыгызны җылытсын» дип җылы сүзләр дә язам. Керәннән кабымлык, тәмләткечләр әзерлим. Бер витамин бит! Чәйләр беткәч, тагын тегүгә тотыначакмын.

Олысы гына түгел, кечесе дә булыша Нурлатта. Шәһәрнең 2 нче мәктәбе укучылары фронтка кием өлгеләре кисәргә, тегәргә булыша. Бу эштә 30 укучы катнаша. Арада кызлар да, малайлар да бар.

– Тегүчеләр тукыма китерсә, 5–10 сыйныф укучылары толстовка, футболка һәм башка кием өлгеләре сыза. Тәнәфестә дә, дәрестән соң да тик тормыйбыз. Пионерлар бүлмәсенең ишеге һәрвакыт ачык. Тукыма, кайчы, акбур – барысы да әзер. Балаларның хезмәтен махсус төркемгә куябыз. Тегүчеләр, шул өлгеләрне кулланып, кирәкле әйберләрне тегә. Вакыт булганда, штабка барып кисәргә, тегәргә, киемнәр төргәкләргә дә ярдәм итәбез, – диде педагог-оештыручы Айгөл Сәлахова.

Сәрия МИФТАХОВА

**Ватан хакына**

# «Бераү дә онытылмасын»

**Махсус хәрби операция зонасыннан вакытлыча туган якларына кайткан Татарстан егетләре кыска гына ялларын заяга уздырмый. Район башлыклары белән очрашуларда катнашалар, үзләрен һәм якыннарын борчыган мәсьәләләрне җиткерергә тырышалар. Районнар бу җәһәттән ниләр эшли? Без шуны белештек.**

### Зәй

Зәй районы башлыгы Разиф Кәримовның вакытлыча ялга кайткан хәрбиләр белән чираттагы очрашуы җырлы-моңлы рухта узды. «Энергетик» мәдәният сараенда узган чарада район активистлары һәм солдатлар өчен кечкенә концерт әзерләгәннәр иде. Шуннан соң Разиф Кәримов аларга районлагы хәлләр турында сөйләде.

– Сез кайтканчы, район икътисадында тотрыклылыкны сакларга вәгъдә биргән идек – сүзебездә торабыз. Елны яхшы нәтиҗәләр белән тәмамлыйбыз. Районнан җәмгысы 250 тонна гуманитар йөк, шул исәптән 10 машина җибәрелде. Безгә мөрәҗәгать иткән гаиләләрнең гозерләре үтәлә, – диде ул, егетләрнең җиңү белән кайтуларын теләп.

**Сүз уңаеннан, Зәйдәге «Масксети» волонтерлар төркеме бер еллыгын билгеләп үтте. Шушы вакыт дәвамында алар махсус хәрби операция зонасына 1000 маскировка челтәре үреп җибәргән. «Аларның гомуми мәйданы – 14 мең кв. км. Кечкенә генә Зәй өчен бу – шактый зур эш», – диде әлеге төркемнең координаторы Елена Хисаметдинова.**

### Алабуга

Шәһәрдә махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм йөзеннән «Вместе к Победе» хәйрия концерты узды. Концертның режиссеры Илсаф Хәлиуллин сүзләренчә, әлеге чара бердәмлекне күрсәтүе белән дә әһәмиятле.

– Хәзерге көндә бердәмлекне саклау бик мөһим. Бу җәһәттән файдалы була алуыма бик шатмын, – ди ул.

Алабугада яшәүчеләр әлеге концертта 150 мең сум акча җыйган. Әлеге акча хәрбиләргә ярдәм өчен тотылачак.

### Түбән Кама

Түбән Камада «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстан буенча филиалы җитәкчесе Гүзәл Удачина шәһәр җитәкчелеге һәм вакытлыча ялга кайткан хәрбиләр белән очрашты.

– Беркем дә игътибардан читтә калырга тиеш түгел. Туганнарын һәм якыннарын югалткан гаиләләргә ярдәм күрсәтү дә безнең өчен бик мөһим. Моннан тыш, тыныч тормышка кире кайткан егетләрне дә онытмаска кирәк, – диде район башлыгы Рамил Муллин.

Гүзәл Удачина фондның Түбән Кама филиалы эшчәнлеге белән дә танышты. Филиал урнашкан бина техник яктан тәэмин ителгән. Рамил Муллин монда психолог эшли торган «эмоциональ бушану» бүлмәсе дә ачарга тәкъдим итте.

Шуннан соң узган очрашуда махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә каралган ярдәм чаралары турында фикер алыштылар. Гүзәл Удачина чарада катнашкан хәрбиләргә рәхмәт белдерде һәм «Ватанны саклаучылар» фондыннан истәлекле бүләкләр тапшырды.

Ярдәм димәктән, ел дәвамында Түбән Камадан махсус хәрби операция зонасына 50 тоннадан артык гуманитар ярдәм җибәрелгән.

– Түбән Кама волонтерлары маскировка челтәрләре, носилкалар һәм башка кирәк-ярак әзерләү өчен цехлар оештырды. Аларны әзерләү өчен материаллар хәйриячеләр, битараф булмаган кешеләр һәм Түбән Кама волонтерлык үзәгенең хәйрия счеты исәбеннән сатып алына, – диде Түбән Кама шәһәре мэры урынбасары Марина Камелина.

Хәзерге көндә районда гуманитар йөкнең чираттагысын әзерлиләр. Бу юлы әлеге эшне шәһәрнең сәнәгать оешмалары башлаган. Ярдәм төялгән йөкне махсус хәрби операция зонасына, Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә 12 декабрьдә җибәрергә ниятлиләр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

# КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты,

**туганы**

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Документлар белән эшләү идарәсе Татарстан Республикасы Хөкүмәте актларын теркәү бүлеге баш белгече Зәйнуллина Зөлфия Әкрам кызының авыр кайгысын уртаклаша.




ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНҮ, ДӘВАЛАНУ һӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ һӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ һӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ һӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР һӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

# СЕУЛДА «ӘПИПӘ»НЕ ӘЙТТЕРДЕЛӘР

**Арабыздан беребез**

**Кем дисезме? Арча балалар сәнгать мәктәбендә җыр укытучысы Гөлнара Гәрәева ул. Кызы белән сәяхәттә йөргәндә, манарасы күккә ашкан бер корылма эчендә ап-ак пианино күргән дә түзә алмаган: беренче күңеленә килгән «Әпипә»не уйнап җибәргән. «Татар көен бик яраттылар, яныма килеп, бу – нинди көй, дип сораучылар да булды», – ди ул. Сөйләшә торгач ачыкланды: бармаклары юкка гына «Әпипә»гә тартылмаган аның. Шул җәһәттән без Гөлнара ханым белән нәселдән килгән сәләт, аны үстерү турында да сөйләшеп алдык.**

### Нәселдән килә

– Мин, Арчада туып, балачактан татар моңнарын тыңлап үстем, – дип башлады ул сүзен. – Күп нәрсә, шул исәптән сәләт тә нәсел-нәсәпкә бәйле икән ул. Тик аны вакытында тотып алырга, баета белергә генә кирәк. Балаларга кагылганда бигрәк тә. Әнием гел җырлый иде минем, эшләгәндә дә, ял иткәндә дә, күзләрен еракка төбәп, уйланып утырганда да. Үзем дә сизмәстән, мин дә аңа кушылып китә идем. Өч яшемдә пианино каршына утырганмын да «Әпипә» көен җыя башлаганмын. Шунда әти-әнием киләчәктә кем буласымны тәгаенләп куйганнар. Аннан өйдә аккордеон пәйда булды. Анда да үземә ошаган көйләрне чыгара башладым. Соңрак музыка мәктәбе, Арча педагогия училищесы, Казан педагогия институтының музыка факультеты… Һөнәрле булгач та, Арчадан аерылуны күз алдыма китерә алмадым. Педагогия училищесына музыка укытучысы булып кайттым. Булачак ирем Шәүкәт белән (ул – Апас районындагы Олы Бакырчы авылыннан) Казанда танышкан идек. Ул, рәхмәт яусын инде, теләгемә каршы килмәде, училищеда 35 ел буена тарих фәнен укытты. Бик күп шәкертләре, тарих укытучысы белгечлеген алып, эшен дәвам иттерә. Төрле өлкәләрдә булсак та, икебез дә – иҗат кешеләре без. Безне бу бик берләштерә. Шәүкәт агач эшен ярата. Үз куллары белән мебель ясый, мунчаны да үзе төзеде. Аның да сәләте нәселдән килә: бабасы да, әтисе дә балта осталары булган.

Дөрес, улыбыз Илшат үз сукмагын ярды, ул банкта эшли. Ә менә кызыбыз Миләүшә үзенә кирәген ике яктан да эләктергән булып чыкты. Без аны музыка мәктәбенең сәнгать бүлегенә биргән идек. Анда ул композиция, рәсем сәнгате буенча дәресләр алды. Укытучысы Райлә Фәтхуллина белгечлекне дөрес сайларга ярдәм

**«Мин кызымның ярдәме белән дөнья буйлап сәяхәт итәм», – ди Гөлнара ханым.**

итте. 11 нче сыйныфны тәмамлагач, кызыбыз Казан дәүләт архитектура һәм төзелеш институтының «Архитектураны проектлау» факультетына укырга керде.

### Сәләт сәяхәткә юл яра

Бала яраткан һөнәрен үзләштерсә, акча да эшли алыр, үзенә дә рәхәт булыр, әти-әниләргә дә ярдәме тияр, дип уйлый Гөлнара ханым. Париж, Марсель, Лион, Берлин, Дрезден, Гамбург кебек шәһәрләрдә сәяхәт итә алуын да ул дөрес тәрбиянең нәтиҗәсе дип саный. 2016 елда Миләүшә Казан университетын кызыл дипломга тәмамлый да Берлин техник университетының магистратурасына укырга китә. Андагы мөгаллимнәр кызның кул графикасы белән рәсем ясау мәктәбенә югары бәя бирәләр. Инде укыган вакытта ук Европа илләрендәге төрле фирмаларда – Копенгаген, Берлин, Париж, Роттердам шәһәрләрендә стажировка уза. Магистратураны тәмамлагач, аны дөньяда иң абруйлы оешмаларның берсе булган ОМА Нидерланд архитектура бюросына эшкә чакыралар. Шуннан Гөлнара ханымның төрле илләргә сәяхәтләре башлана да инде. Командировкаларга чыкканда да, ял вакытларында сәяхәт иткәндә дә Миләүшә, җаен табып, әнисен үзе белән алырга тырыша. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың дигәндәй, йөри торгач, Гөлнара ханым да архитектура белән кызыксынып китә. Бу юлы да алар, нигездә, Сеулдагы төзелешләрне карап йөргәннәр.

– Көньяк Кореядагы матурлыкка сокланып туймаслык, – ди Гөлнара ханым. – Лотте-Уорлд манарасы – әкияттәгедәй күккә ашкан иң биек корылма. Ул 123 катлы. Биеклеге – 555 метр. Кенбоккун сарае Чосон династиясе идарә иткән елларда (1392–1897) төзелгән. Ул хәзер дә иң зур биш сарайның берсе булып санала. Аннан ерак түгел тау башында, шәһәр үзәгендә Букчон-Ханок авылы урнашкан. Аның төзелгәненә алты гасырдан артык икән инде. Сеулның тагын бер байлыгын әйтми кала алмыйм. Ул – Тондэмун-Дизайн-Плаза. Метро, музей, күргәзмәләр, кибетләрне үз эченә алган, җәяү йөри торган урыннары да бар. Кыскасы, тарих та саклана, бүгенге яңалыклар да барлана Көньяк Кореяда.

### Матурлыйсы иде

– Затлы урыннарны күреп кайткач, туган җиребезне дә матурлыйсы килә. Бу хакта кызым белән дә сөйләшәбез, ул да хыяллана. Тик әлегә төрле сәбәпләр белән мөмкинлекләр юк, – ди Гөлнара ханым.

Ә үзе булдыра алганча дөньяны матурларга тырыша ул. Музыка мәктәбендәге укучылары белән Татарстан, Россиянекендә генә түгел, халыкара бәйгеләрдә дә катнаша. Еш кына призлы урыннарга да лаек булалар. «Татарстан тавышы», «SFORZANDO музыкаль премиясе», «Созвездие-йолдызлык» конкурсларында бигрәк тә теләп катнашалар. Аларны еш кына «Шаян ТВ»да да күрергә була.

– Шундый талантлы балалар бар. Татар көйләрен дөнья киңлекләренә таратырлар әле, – дип өметләнә Гөлнара ханым. Шул җәһәттән әти-әниләргә дә киңәшләрен бирергә онытмый.

Гөлнара ханым – Арча район мәдәният йортында да үз кеше. Ул анда «Русская песня» халык ансамблен җитәкли, үзе үк дирижерлык та итә. Тиздән бу коллективның ярты гасырлык юбилеен үткәрергә җыеналар. Аларны да һәр җирдә күрергә була: «Каравон», «Момент ARTа» ветераннарның «Балкыш» фестивальләрендә, «Татарстан – безнең йорт» бәйгесендә…

Ничек барысына да өлгерә, дисәгез, Гөлнара ханым сәламәт яшәү рәвеше алып бара: йөгерә, йөзә, чаңгыда йөри… Татарстан, Россия шәһәрләре буйлап сәяхәт итәргә дә вакыт таба. Тирә-юньдә матурлык тудырырга омтылган кеше хәрәкәттән башка яши алмый инде ул.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

# ӘТИ НӘСЫЙХӘТЕ

**Гомере буе балаларга белем биреп, бүген дә мәктәп тормышы белән кызыксынып яшәгән олпат шәхес Мирзанур Галимовның эш-гамәлләре дә, фикерләре дә хөрмәткә лаек.**

– Мин – коеп куйган крестьян баласы. Әтием бик оста тимерче иде. Әнием төрле эшләрдә эшләде, – дип, үзе белән таныштырды ул. – Әтием 1942 елда фронтка китте дә безнең янга кире әйләнеп кайтырга насыйп булмады. Аны озатканда мин икенче сыйныфта укый идем. Соңгы очрашуыбызда әйткән сүзләрен гомерем буе күңел түрендә саклыйм һәм ул әйткәнчә эшләргә тырыштым. Кыш. Февраль иде ул. Әти белән тагын дүрт ир-ат яуга кузгалды. Авыл башына кадәр печән түшәлгән агач чанага мин дә утырып бардым. Авылны чыккач, әти мине көчле кулларына күтәреп алды да озак кына төшерми торды. Шул вакытта үгет-нәсыйхәтен дә әйтте: «Улым, беренчедән, әниеңне тыңла. Икенчедән, әйбәт укы. Өченчедән, тәмәке тартма».

Әтисе китә, үгет-нәсыйхәте улының йөрәгендә кала. Ун яшеннән әтисез калган малай гомере буе аның каберен эзләп табу хыялы белән яши. Берничә тапкыр омтылыш ясап карый, тик нәтиҗәсе булмый. Ниһаять, 50 елдан соң гына ул газизенең каберенә барып, дога кылу бәхетенә ирешә. Бабаларының каберен зиярәт кылырга Мирзанур абыйның уллары Алмаз белән Марсель һәм хатыны Люция дә бара. «Күңел җиңеләеп китте», – ди Мирзанур ага бу уңайдан.

Әтисенең «Яхшы укы!» дигән сүзләрен дә исеннән чыгармый, мәктәптә бик тырышып белем ала ул.

– Мин умартачы буласы идем, тик әнине иске генә йортта калдырып чыгып китә алмыйча, авылда калдым. 10 нчы сыйныфны тәмамлагач, чәчү чәчкәндә агроном абзый: «Мирзанур энем, син бит бик яхшы укыдың. Нигә укырга китмисең?» – диде. Бу август башлары иде, берничә көннән имтиханнар башланасы. Өйгә кайткач, бу турыда әни белән апага сөйләдем, – дип искә алды Мирзанур абый.

Әнисенең ризалыгын алгач, табигый география юнәлеше буенча укырга теләп, уку йортына юнәлә. Тик кеше күп булу сәбәпле, документларын кабул итмиләр егетнең. Ләкин юлына укытучысы килеп чыгып, математика буенча имтихан бирергә кертеп җибәрә. Сынауларны яхшы гына узып, математика укытучысы булырга укый. Аны тәмамлагач, Мөслим районының Табын авылына көчле мәктәпкә юллыйлар. Иң усал, шук балалар эләгә үзенә. Тик яшь булуына карамастан, алар белән дә уртак тел таба. Бераздан Мари-Бүләр авылы мәктәбенә күчә. Шуннан армия хезмәтенә алына. Аннан соң Метрәй авылына кайта.

– Тормыш кушуы буенча, мине берара Иркәнәшкә укытырга җибәрделәр. Дәрескә кергәч, бер баланың парта астында утыруын күрдем. «Әллә берәр нәрсәң төштеме? Төшкән булса, ал да урыныңа утыр», – дидем. Бу бала торды да: «Миңа башка укытучылар шикелле кычкырсаң, партаны күтәреп бәрә идем», – ди. Шаккаттым. Аннан соң теге баланың дәресе хәзерләнмәгәне ачыкланды. Анысын да ачуланмыйча гына бергә эшләдек, – дип искә алды Мирзанур Галимов яшьлек елларын.

Дәрестән соң укытучы баланың өенә барырга була. Бергә утырып, дәресләрен хәзерлиләр дә, укытучы өенә кайтып китә. Икенче көнне бөтен мәктәпнең һәм авыл халкының телендә шушы вакыйга гына була. Яшь укытучы авыл халкы каршында хөрмәт казана. Теге укучы да тырышып укый башлый. Укытучының сүзе һәм гамәле менә нинди тәрбия биргән.

– Укытучы булып эшләгән чорның иң рәхәт вакыты Мари-Бүләр авылы мәктәбендә эшләгән еллар булгандыр. Чөнки мин анда пионервожатый идем. Балалар белән яратып эшләдем. Аннан соң Метрәй мәктәбендә дә бик рәхәт эшләдем. Монда алты ел укыткач, мәктәп директоры итеп билгеләделәр мине. Мәктәп иске иде. Калинин исемендәге колхоз рәисе Яхъя Абдуллин белән киңәшләшкәч, яңа бина салдык. Ул бары тик колхозчылар ярдәме белән генә сафка басты. Балаларның ашавын да хуҗалык тәэмин итте, бер тиен дә акча алмадык, – ди Мирзанур абый.

32 ел мәктәпне җитәкләгәндә прораб та, электрик та, склад мөдире дә, хисапчы да – барысы да булырга туры килә үзенә. Өйгә кайтып керүләр дә сирәк эләгә.

– Мирзанурның эштән кайтып кергәне булмады аның. Укыту гына түгел, хуҗалык эшләрен дә җайларга кирәк бит. Коллективын тәэмин итте. Йорт та, балалар да минем җаваплылыкта иде. Ләкин әлеге авырлыкларга карамастан, Мирзанур белән яшәү бик рәхәт булды. Мин аңа берни дә әйтә алмыйм. Ул – минем алтын баганам, – дип сүзгә кушылды тормыш иптәше Люция апа.

Менә шулай бер-берсен аңлап, санлап, кадерләп яши Галимовлар. Тиздән 92 яшен тутырачак Мирзанур абыйга сокланмыйча карау мөмкин дә түгел. Камил, аек акыллы, оста, төпле фикер йөртүче аксакал белән рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык.

– Тормышың әйбәт, гомерең озын булсын өчен, беренчедән, актив тормыш алып барырга, кешеләр белән аралашып яшәргә кирәк. Икенчедән, гаиләңдә тынычлык булсын. Мин Люция апагызга бик рәхмәтле. Алар әни белән 47 ел бик тату яшәделәр. Кайвакыт минем җитешсезлегем булса, икәүләп ачуланалар иде. Әле шул 47 елның 30ын әни сукыр булып яшәде. Люция бер авыр сүз әйтмичә тәрбияләде аны, – диде Мирзанур абый.

Озын тормыш юлында уңышлар, дәрәҗә, җиңүләр белән бергә сынаулары да янәшә атлаган. Ике балаларын япь-яшь килеш җир куенына салу исә әти-әни күңелендә аеруча тирән эз калдырган. Башта студент кызлары фаҗигале рәвештә һәлак була, аннан соң әтисенең юлын дәвам иттерүче уллары Марсель янып-көеп эшләгәндә кинәт кенә авырып үлә. Бүген төп таянычлары – уллары Алмаз Казан федераль университетының Психология һәм мәгариф институтында эшли.

– Бу – минем икенче, өченче буын бабаларымның ишегалды. Без киткәч, аны саклап, карап тоту – улыбызның бурычы, – ди кадер-хөрмәттә гомер итүче өлкәннәр.

Бүген дә мәктәп хәлләре белән танышып, элек бергә эшләгән хезмәттәшләре белән аралашып яши Мирзанур абый. Ул анда – кадерле һәм көтеп алган кунак.

> – Хәзерге укытучыларга мәктәптә эшләү авыррак. Элек юклык заманында балалар тәрбияле иде. Хезмәттән башка берни дә булмаганны күреп, белеп үсте. Ә хәзер барысы да бар. Заманында мәктәптә хезмәт һәм тәрбия сәгатьләрен бетерү җинаять дәрәҗәсендәге ялгышлык булды. Бу мәгариф системасын юкка чыгаруга тиң иде. Дөрес, алар кире кайтты. Анысына сөендем менә, тик күпне югалтмадык микән инде? Хәзер балалар укытучыны хөрмәт итми. Шуңа күрә укыту авыр. Хәзерге укытучыларга сабырлык телим. Әле ярый мин вакытында пенсиягә чыгып калганмын дим. Чөнки холкым буенча шактый кырыс кешемен, – ди әңгәмәдәшем.

Хәер, Мирзанур абыйның әле дә тәрбиядән туктаганы юк. Ул бүген мәчеттә мәхәллә әгъзасы булып тора, авылдашларына вәгазьләр укый. Киңәш-табыш итәсе кешеләр дә аларның йортларына сукмакны яңартып кына тора.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Сораштыру

## НИХӘЛЛӘРДӘ ЯТАСЫЗ?

**Җәвит ШАКИРОВ,**
**Татарстанның халык артисты:**
– Сөенечле көннәр әле. Икенче китабымны чыгардык. Беренче шигырьләр җыентыгым «Минем күңел» дип аталган иде. Монысы – «Моңлану». Концертлар белән йөрибез. Әлегә гастрольдән кайткан вакыт. Зөлфия апагыз белән дә бар да тәртиптә. Оныклар тәгәрәп үсә. Шөкер, өчәү бит инде алар бездә! Күптән түгел Зөлфия белән Кисловодск шәһәрендә ял итеп кайттык. Беренче баруыбыз иде. Бик ошаттык. Эш бик күп. Сөенерлек кенә. Яңа ел съемкалары башланды.

**Гөлгенә ГЫЙНИЯТОВА, пенсионер**
**(Биектау районы Дөбьяз авылы):**
– Сәламәтлегемне кайгыртып йөрим әле. Быелга бакча эшләре бетте. Урнаштырасын урнаштырып куйдык. Кичләрен маскировка челтәре үрергә дә йөрим. Бик тә бәйләргә яратам. Буш вакытым булдымы, тизрәк җеп тотам. Тегүче булып эшләгән идем. Пенсиягә чыкканда, балаларым тегү машинасы бүләк итте. Башта үзебезгә, дусларга гына дип урын-җир комплекты тегә башлаган идем. Хәзер инде заказга да сорыйлар. Көн саен йоклар алдыннан китап укыйм. Китапханәдәге бөтен татар китапларын укып бетердем. Авылга концертлар килсә, аны да калдырмыйм. Кыскасы, моңаерга, картаерга уйламый да әле күңел.

**Гөлназ ШАКИРҖАНОВА, биш бала әнисе**
**(Балтач районы Куныр авылы):**
– Күпләп умарта тотабыз. Ел буе бал кортлары янында инде без. Бал күп булды. Әле дә сатабыз. Районда һәр чәршәмбе «Атнакич базары» эшли. Шунда барабыз. Өч игезәк малаебызга 4 яшь тулып китте. Күзгә күренеп үсәләр. Балалар бакчасына йөриләр. Унга кадәр саный беләләр. Бик тату-дус алар. Шуларга карап күңел сөенә. Улыбыз белән кызыбыз мәктәптә укый. Әле мин районда үтә торган «Әниемә» бәйгесендә катнашам. Анда җиңүчене тавыш санына карап ачыклыйлар. Буш вакыт булса, телефонда шул хәбәрне кешегә таратам. Шөкер, беренче торам. Минем өчен тавышны күп биргәннәр. Катнашкач, җиңәсе килә бит.

**Лилия МУСИНА, иминият хезмәткәре**
**(Мамадыш районы Түбән Яке авылы):**
– Бу арада йортларын, машиналарын иминиятләштерүчеләр күп. Өйләренә дә барам, үзләре дә киләләр. Авылда торгач, малларсыз да булмый. Үгезләребез бар. Аларны суеп, итләрен урнаштырырга җыенабыз. Әлегә иткә заказ җыябыз. Ике ботына булды инде, икесенә юк әле. Сыерларыбызны савып, сөтен тапшырабыз. Әле дә алар бар, дим. Җәен сөт акчасы шактый җыела бит. Бездә хәзер сөтнең бер литрын 25 сумнан җыялар. Күрше авылларда 26 сумга да җыялар икән. Көненә 20 литр сөт тапшырам. Иш янына куш инде. Маллар гына исән-сау булсын.

Экология

## *Татарстан тагын беренче!*

Бөтенроссия «Россия суы» елга буйларын җыештыру бәйгесенә нәтиҗә ясадылар. Быел да Татарстан беренчелекне алды. Исегезгә төшерәбез: әлеге бәйге «Экология» илкүләм проектының «Уникаль су объектларын саклау» федераль проекты кысасында үткәрелә. Җиңүче дипломын Татарстанның экология һәм табигать министры урынбасары Егор Тарнавскийга Мәскәүдә «Россия» халыкара күргәзмә-форумында тапшырдылар. «Татар-информ»да узган очрашуда Егор Тарнавский әлеге бәйге турында гына сөйләп калмады, тирә-якны чистарту буенча үткәрелгән башка чараларга да нәтиҗә ясады.

– Җиңү түгел, әлеге бәйгедә беренчелекне саклау авыррак, – ди министр урынбасары. – «Россия суы» бәйгесендә без инде өченче мәртәбә җиңү яуладык. Әлеге чараны республикада яшәүчеләр бик яратты. Алар анда теләп катнаша. Татарстан – сулыкларга бай төбәк. Республика мәйданының 6,4 процентын су алып тора. Әнә шуңа да кешеләр күлләр, инеш-елгаларның чисталыгына битараф түгел. Алар аңлый: чисталык һәркемнең үзеннән тора, – ди Егор Тарнавский.

Министр урынбасарын яшь буынның тирә-якка булган игътибары да сөендерә. Моңа мисал итеп ул «Мәктәп экопатруле» акциясен китерде. 2020 елдагы коронавирустан соң бәйге сүлпәнәйгән кебек була. Быел исә гариза бирүчеләрнең саны 7 меңнән артык.

– Бәйгегә барлыгы 7349 гариза килде. Бу узган ел белән чагыштырганда ике мәртәбә күп. Әлеге саннар безне сөендерә. Яшь буынның экологияне кайгыртуына без шатбыз, – ди министр урынбасары.

Сүз уңаеннан, «Мәктәп экопатруле» мобиль кушымтасы 2014 елдан бирле эшли. Укучылар шуның аша министрлыкка чүплекләр хакында хәбәр җибәрә. 9 ел эчендә министрлыкка укучылардан 46 мең хәбәр килгән. Күптән түгел 80 укучыны билгеләп үттеләр. Алар барысы да диплом һәм кыйммәтле бүләккә лаек булды.

Егор Тарнавский иске батареяларны җыеп тапшыручыларга рәхмәт белдерде. Баксаң, соңгы 5 ел эчендә кулланышта булган 145 тоннадан артык батарея тапшырылган. Җир-ананы саклауга нинди зур өлеш кертелгән. Бер очрашуда министр Александр Шадриков: «Җиргә ташланган бер батарея 1 керпене үтерә», – дигән иде. Баксаң, аннан чыккан зарарлы матдә 1 керпе, 1 сукыр тычкан, 1 мең яңгыр суалчанын үтерергә сәләтле икән. Менә шуннан уйлап карагыз инде!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

**Сан**

Быел «Россия суы» акциясе кысасында Татарстанда елга ярларын чистартуга **323 мең** кеше чыккан. Алар, **9 мең** чакрым араны чистартып, **22 мең** кубометр чүп җыйган. Бу акция 2014 елдан үткәрелә. Шунан бирле Россия күләмендә елга буйларын чистартуга **9,5 миллион кеше** чыккан, 10,9 миллион капчык чүп җыелган.

# ХА-ХА-ХАНӘ



*Шушы урында көләсе*

**Мач әйткән!**

**Андрей ДЕРЖАВИН, җырчы:**

– Хит килә дә китә, ә җыр кала.

## Көлке – дәва

Стоматолог:
– Курыкма, Илнур, бөтен нәрсә дә кайчандыр беренче тапкыр була.
– Мин Илнур түгел.
– Беләм. Мин – Илнур.

Элек бахилларсыз гына ничек дәваландык икән без, дип шаккатам.

– Доктор, мин үземне әллә ничек кенә хис итәм.
– Эчәсезме?
– Юк.
– Тартасызмы?
– Юк.
– Алайса, аңлашылды.

– Сез ник 80 яшьлек әбигә «сез авырлы» дип әйттегез?
– Аның караве ул тотлыкмый башлады.

– Доктор, бу авырудан ничек дәваланырга?
– Хәзер, интернеттан карыйм.
– Бәлки, үзем карармын?
– Үз-үзеңне дәвалау белән шөгыльләнмәгез.

## Очлы күзәтүләр

Дөньяда иң рәхәт әйбер ул – йоклау. Һәм, иң мөһиме, ул бушка.

Мәче – иң яхшы дус! Төнгә каршы ник ашыйсың, дип әйтмәячәк, ә бергә утырып ашаячак.

Акча айдан тизрәк бетә.

Кайбер чаралар шулхәтле пүчтәк, башыңны юып барганың әрәм.

Сизгәнегез бармы, әҗәтне кире алганда үзеңне мескен итеп тоясың, ә әҗәт кайтаручы – герой!

Өеңне кечкенә дип уйлыйсыңмы? Аны җыештыра башла.

Боксерларның шаярулары еш кына билдән түбән була.

«Монда акчаны пачкасы белән салыгыз», – дип шаяра банкомат.

Сине битараф тыңлаучылар йорт сыман. Тәрәзәдә ут бар, ә өйдә кеше юк.

Санторинига барырга акчаң җитмәсә, санаторийга гына барасың.

Үскәч, иң авыр сорау – «Бүген нәрсә пешерим икән?» Һәм бу сорауга көн саен җавап табасы.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Юмореска

# ТЕЛЕВИЗОР КАРАГАНДА...

Авылларда телевизор карый башлаган чор. Иң беренче булып яңа әйберне бездә минем бабам Зиннур Хәмзин алып кайта торган иде. Велосипед белән шулай булды. Шаккаттылар инде. Аннан соң без беренче телевизор алып кайтучы булдык. Аңа антенна баганасы кую – үзе бер мәзәк. Багана ничаклы озын, ягъни биеккә куела, телевизор шулхәтле әйбәтрәк күрсәтә икән. И-и, аны торгызганда кешенең күп җыелуы, төптән чокырга батырып, сәнәк-тырма, терәгечләр белән көчәнә-көчәнә күтәрәләр, ә ул сыгылып, антенналы башы җирдән дә калыкмый. Кыскартырга мәҗбүрләр. Шулай итә-итә барыбер бастырып куялар. Боргычлап, канал көйләү өчен дә чөй кагалар. Кереп карыйлар өйгә, әһә, күрсәтә – кар яуган кебек, әмма нәрсәдер шәйләргә була. «Хәмзиннәр телевизор алганнар, инде күрсәтә дә икән», – дигән хәбәр бөтен авылга тарала. Бөтенесе килеп карап чыгалар. Әти, әни, без – балалар карап утырабыз инде – нәрсәдер бар экранда. Күрсәтә бит инде, тагын ни кирәк?! Килгән-күргән кеше: «Әйбәт икән, безгә дә алырга кирәк булыр», – дигән фикергә килеп, кайтып китәләр.

Озак та үтмәде: «Хафизлар алган икән», – дигән хәбәр таралды. «Аларныкы әйбәтрәк күрсәтә!» – диләр. Киттек шунда. Халык җыелган, антенналары куелган – биегрәк. Шулай да экраны карлы. Нәрсәдер шәйләнә. Озаграк карап утырсаң, ни дә булса аңлый да башлыйсың. Хафиз абзыйның йөзендә горурлык – телевизор алган бит! Бу утырды-утырды да әйтә:

– Ярый, сез карый торыгыз, мин мунчага киттем, апагыз Саҗидә көтеп торадыр, – ди. Хатыны инде.



Ул китеп күп тә үтмәде, телевизор, «чыж-ж» итеп, гөрләргә тотынды.

Шул вакыт моңа хәтле тыныч кына карап утырган Бәгъданур Хиннуры:

– Ах, анасын сатты, Хафиз, үзләренең мунча кергәнен күрмәсеннәр дип, кызган ташка су сипте! – диде.

Менә шулай, бездә «Хуҗа Насретдин»нар бик күп.

Алмаз ХӘМЗИН

Үзирония – кирәкле шәйдер

Шуны аңладым: күбрәк йоклаган саен, акча да азрак туздырыла икән.

◆◆◆

– Безнең фирманың шартлары буенча, сез үзегезнең хезмәт хакы күләмен берәүгә дә әйтмәскә тиешсез.
– Алай мескенләнергә җыенмаган идем дә.

◆◆◆

– Эх, яшьлегемне кире кайтарыр идем! Бу тормышны бөтенләй башка төрле хаталар ясап яшәп карар идем.

◆◆◆

«Мин – прокурор малае!» – дип кычкыруым аюны берничек тә куркытмады.

◆◆◆

– Нигә соңга калдың?
– Өйдән соң чыктым.
– Ә иртәрәк чыга алмадыңмы?
– Иртәрәк чыгарга соң иде инде.

◆◆◆

– Сәерлек шкаласы буенча син кайсы урында?
– Мин – шул шкаланың үзе.

◆◆◆

– Бу эшне башкару өчен сиңа күпме вакыт кирәк?
– Бер сәгать эчендә эшләп атармын, дип уйлыйм атна дәвамында.

◆◆◆

Иртәгәдән бөтен нәрсәне иртәгәгә калдыру гадәтен ташлыйм.

◆◆◆

Табигать миңа юмор хисе бүләк иткән. Бүләкләр шуның белән тәмам.

## ИРЛӘР ҺӘМ ХАТЫННАР



– Гафу, иртәгә күрешә алмабыз.
– Ник?
– Әле уйлап тапмадым.

▼▼▼

– Мин бернәрсә дә әйтергә теләмим, әмма...
– Әмма әйтәчәксең.
– Әйе. Әмма әйтәчәкмен...

▼▼▼

– Синең егетең бармы?
– Юк.
– Шундый чибәр кызның ничек егете юк инде?
– Ирем кушмый.

▼▼▼

Ике тапкыр гаилә корып карадым, икесе дә нәтиҗәсез. Беренче хатыным миннән китте. Икенчесе китмәде.

▼▼▼

– Карале, йолдыз атыла, теләк телә!
– Син туры юлга бассын дип телим.
– Йолдыз түгел, самолет икән.

▼▼▼

Элек йөргән егетемнең әти-әнисе лалә чәчәкләре үстерү белән шөгыльләнә иде. Ул егет миңа нинди чәчәкләр бүләк итә иде, дип уйлыйсың? Әйе, берниндине дә бүләк итми иде.

▼▼▼

– Син мине хәтерлисеңме?
– Ычкын моннан!
– Хәтерлисең икән әле.

▼▼▼

Мин хатын белән гел фикер алышам. Үз фикерем белән киләм, аныкы белән китәм.

▼▼▼

Ник миңа язмый икән ул, күрмәмешкә салышыр идем.

## ГАИЛӘ ХӘЛЛӘРЕ

– Алло, әни, мин әтинең машинасын кырдым.
– Тагынмыни? Хәзер зәңгәр фломастер алып чыгам.
– Бу юлы зәңгәр ишек алып чык.

* * *

– Әгәр сиңа кул күтәрәләр икән, күрәк белән сук.
– Әти, мин бит – кыз кеше.
– Алайса, алсу төстәге күрәкне ал.

* * *

Мин шундый өлкән яшьтә ки, сдачаны шырпы белән биргән заманнарны хәтерлим.

* * *

– Әни, миңа чупа-чупс ал әле.
– Сиңа – 27.
– Юк, берәү җитә.

* * *

– Бүгенге балаларга нәрсә бүләк итеп шаккатыра аласың?
– Берни алмасаң гына шаккатырып булыр.

* * *

Дәресләрне әзерләп бетермичә, миңа йокларга ятарга ярамый. 37 яшемдә болай булыр дип уйламаган идем.

* * *

Шундый иттереп яшә – подъезд әбиләре синең артыңнан ук йөрсен.

* * *

Әни кеше телефоннан энесе белән сөйләшә. Буыннары авыртудан зарлана. Энесенең дә буыннары авырта икән. Моны тыңлап торган әти кеше әйтеп куя: «Бөтен партиягез брак булган».

* * *

– Хатыннар өчен иң яратмаган сүз нинди?
– «Карарбыз».

* * *

– Матурым, йөрәгем әллә нишләде, «Ашыгыч ярдәм» чакырт әле тизрәк.
– Телефонда пароләң нинди?
– Тукта, нормальләштем бугай.

* * *

Хатын ирне һәрвакыт үсендереп торырга тиеш. Бигрәк тә үзе эшлисе килмәсә.

Әз-мәз мәзәк

– Алло! Сез эш эзлисезме?
– Әйе.
– Тапкач, шалтыратыгыз әле, кредит алу буенча отышлы тәкъдимебез бар.

* * *

Зебра җәяүле юл кичүендә тельняшка кигән матросны бәргән.

* * *

– Иртән кофедан да яхшырак уята торган нәрсә бармы?
– «Без соңга калдык», – дип кычкыру.

* * *

– Егерме ел элек алган «Айфон»ыма берни булмаган, сәгать кебек эшли.
– Ә яңаны алсаң, смартфон кебек эшләр иде.

* * *

3D-принтер җитештерүчеләр үзләренең продукциясендә 3D-принтер чыгармауны үтенә.

* * *

Мансур үзенең йөргән кызы Лилияне әти-әнисе белән таныштырырга кунакка алып кайтты. Мансурның әнисе, Лилияне күргәч, бик шатланды, алар инде күптән таныш икән, бер парта артында бергә укыганнар.

* * *

– Стратегик фикерләү нәрсә ул?
– Чөгендер ашы ашар алдыннан ак күлмәгеңне салып кую.

**Баш мөхәррир –**
**САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
**Тираж – 5159 данә**
**Гомуми тираж – 13596 данә**
**Газетага сертификат бирелде** Заказ 362

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**
**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+